ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.11.2018 Казан ш. № 7-10/т

Татарстан Республикасы "Лениногорск муниципаль районы" муниципаль берәмлегендә шәһәр яны юнәлешендәге даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында "Спутник" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан башкарыла торган даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның иң чик максималь тарифларын билгеләү турында

"Автомобиль транспорты һәм һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы" 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы һәм “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында" 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары, “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” Федераль законны гамәлгә ашыру турында" 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы "Лениногрск муниципаль районы" муниципаль берәмлегендә шәһәр яны юнәлешендәге даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында "Спутник" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан башкарыла торган даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның иң чик максималь тарифларын әлеге карарга кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының "Татарстан Республикасы Лениногоск муниципаль районында "Спутник" ҖЧҖ тарафыннан күрсәтелә торган шәһәр яны юнәлешендә гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның иң чик максималь тарифларын билгеләү турында" 2011 елның 17 июнендәге 7-25/т номерлы карарының үз көчен югалтуын танырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
карарына кушымта
16.11.2018 № 7-10/т

Татарстан Республикасы "Лениногорск муниципаль районы" муниципаль берәмлегендә шәһәр яны юнәлешендәге даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында "Спутник" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан башкарыла торган даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның иң чик максималь тарифлары

| т/б № | Хезмәт күрсәтү төре | Исәпләү берәмлеге | Тариф (ӨБСны исәпкә алмыйча) |
|---|---|---|---|
| 1 | Пассажирларны йөртү | бер пассажирны илтү өчен бер километр юлга киткән сум (сум/пасс.-км) | 2,30 |
| 2 | Бер багаж урыны өчен | бер километр юлга киткән сум (сум/км) | 0,35 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тарифларны кабул итүне оештыру, тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге